КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 сентябрь г.Казань № 765

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 май, 317 нче; 2014 ел, 24 сентябрь, 670 нче; 2014 ел, 12 ноябрь, 861 нче; 2015 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 2 декабрь, 889 нчы; 2018 ел, 28 май, 404 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә һәм 1 нче пунктта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2014 – 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлында «2014 – 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2021 елларга» сүзләренә алыштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре</td>
<td>
Программаны финанслауның гомуми күләме 33 531 718,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 266 582,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 423 321,1 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан – 30 841 815,4 мең сум.<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барлыгы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Федераль бюджет акчасы</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклар акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>4 813 302,2</td><td>1 273 412,8</td><td>266 582,0</td><td>3 273 307,4</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>4 666 847,5</td><td>1 136 565,5</td><td>0,0</td><td>3 530 282,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>3 891 326,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>3 891 326,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>4 329 307,4</td><td>8 607,4</td><td>0,0</td><td>4 320 700,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>4 760 635,4</td><td>4 735,4</td><td>0,0</td><td>4 755 900,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>5 247 600,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>5 247 600,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>5 822 700,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>5 822 700,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>33 531 718,5</td><td>2 423 321,1</td><td>266 582,0</td><td>30 841 815,4</td></tr>
</table>
Программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммалары чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.<br>
Программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу шартларында Россия Федерациясенең Энергетика министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән ел саен төзелә торган килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;
</td>
</tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 2021 елга тулаем региональ продуктның (алга таба – ТРП) энергия сыйдырышлылыгын чагыштырмача 2007 ел дәрәҗәсенә карата (2021 елда индикатор мәгънәсе 20,26 ш.я.т./млн. сум тәшкил итәчәк) Программаны тормышка ашыру чаралары исәбеннән 26,1 процентка киметү»; |

Программаның II бүлегендә:

6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 нчы таблица

2021 елга кадәрге чорга ТРПның энергия сыйдырышлылыгы индикаторының максатчан мәгънәләре

(ш.я.т./млн.сум)

| Индикатор исеме | 2007 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2007 ел бәяләрендә ТРПның энергия сыйдырышлылыгы | 27,41 | 21,53 | 21,37 | 21,20 | 21,04 | 20,88 | 20,72 | 20,57 | 20,41 | 20,26»; |

6 нчы таблицадан соң килә торган абзацта «2020 елга кадәрге чорга» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 нче таблица

Энергия саклау чараларын үтәү хисабына Татарстан Республикасы районнары өчен энергия сыйдырышлылыгы индикаторының максатчан мәгънәләре

(ш.я.т./млн.сум)

| Икътисадый район, муниципаль берәмлек исеме | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Башкала | 12,85 | 12,68 | 12,51 | 12,34 | 12,18 | 12,01 | 11,84 | 11,68 | 11,51 |
| Арча | 4,59 | 4,53 | 4,47 | 4,41 | 4,35 | 4,29 | 4,23 | 4,17 | 4,11 |
| Әтнә | 3,31 | 3,27 | 3,23 | 3,19 | 3,14 | 3,10 | 3,06 | 3,01 | 2,97 |
| Югары Ослан | 9,13 | 9,01 | 8,89 | 8,77 | 8,65 | 8,54 | 8,42 | 8,30 | 8,18 |
| Биектау | 3,36 | 3,32 | 3,27 | 3,23 | 3,18 | 3,14 | 3,10 | 3,05 | 3,01 |
| Зеленодольск | 10,40 | 10,27 | 10,13 | 10,00 | 9,86 | 9,73 | 9,59 | 9,46 | 9,32 |
| Лаеш | 12,77 | 12,60 | 12,44 | 12,27 | 12,10 | 11,94 | 11,77 | 11,61 | 11,44 |
| Питрәч | 6,54 | 6,46 | 6,37 | 6,29 | 6,20 | 6,12 | 6,03 | 5,95 | 5,86 |
| Казан шәһәре | 10,56 | 10,42 | 10,28 | 10,15 | 10,01 | 9,87 | 9,73 | 9,60 | 9,46 |
| Кама | 38,42 | 37,92 | 37,42 | 36,92 | 36,42 | 35,92 | 35,42 | 34,92 | 34,42 |
| Әгерҗе | 2,72 | 2,69 | 2,65 | 2,62 | 2,58 | 2,55 | 2,51 | 2,48 | 2,44 |
| Актаныш | 1,69 | 1,66 | 1,64 | 1,62 | 1,60 | 1,58 | 1,55 | 1,53 | 1,51 |
| Алабуга | 5,70 | 5,63 | 5,55 | 5,48 | 5,41 | 5,33 | 5,26 | 5,18 | 5,11 |
| Зәй | 6,72 | 6,63 | 6,54 | 6,46 | 6,37 | 6,28 | 6,19 | 6,11 | 6,02 |
| Менделеевск | 2,78 | 2,74 | 2,71 | 2,67 | 2,63 | 2,60 | 2,56 | 2,53 | 2,49 |
| Минзәлә | 3,76 | 3,71 | 3,66 | 3,61 | 3,57 | 3,52 | 3,47 | 3,42 | 3,37 |
| Мөслим | 2,78 | 2,74 | 2,71 | 2,67 | 2,63 | 2,60 | 2,56 | 2,53 | 2,49 |
| Түбән Кама | 57,39 | 56,64 | 55,90 | 55,15 | 54,40 | 53,66 | 52,91 | 52,17 | 51,42 |
| Сарман | 2,86 | 2,82 | 2,78 | 2,75 | 2,71 | 2,67 | 2,63 | 2,60 | 2,56 |
| Тукай | 2,99 | 2,95 | 2,91 | 2,87 | 2,84 | 2,80 | 2,76 | 2,72 | 2,68 |
| Яр Чаллы шәһәре | 13,78 | 13,60 | 13,43 | 13,25 | 13,07 | 12,89 | 12,71 | 12,53 | 12,35 |
| Нефть | 3,29 | 3,25 | 3,21 | 3,16 | 3,12 | 3,08 | 3,04 | 2,99 | 2,95 |
| Азнакай | 2,79 | 2,75 | 2,72 | 2,68 | 2,65 | 2,61 | 2,57 | 2,54 | 2,5 |
| Әлмәт | 3,37 | 3,33 | 3,28 | 3,24 | 3,20 | 3,15 | 3,11 | 3,06 | 3,02 |
| Баулы | 1,31 | 1,29 | 1,27 | 1,25 | 1,24 | 1,22 | 1,20 | 1,19 | 1,17 |
| Бөгелмә | 2,65 | 2,61 | 2,58 | 2,54 | 2,51 | 2,47 | 2,44 | 2,40 | 2,37 |
| Лениногорск | 1,48 | 1,47 | 1,45 | 1,43 | 1,41 | 1,39 | 1,37 | 1,35 | 1,33 |
| Ютазы | 9,99 | 9,86 | 9,73 | 9,60 | 9,47 | 9,34 | 9,21 | 9,08 | 8,95 |
| Көньяк | 2,70 | 2,67 | 2,63 | 2,60 | 2,56 | 2,53 | 2,49 | 2,46 | 2,42 |
| Аксубай | 2,96 | 2,92 | 2,88 | 2,84 | 2,80 | 2,77 | 2,73 | 2,69 | 2,65 |
| Алексеевск | 3,43 | 3,38 | 3,34 | 3,29 | 3,25 | 3,20 | 3,16 | 3,11 | 3,07 |
| Әлки | 3,19 | 3,15 | 3,11 | 3,07 | 3,03 | 2,98 | 2,94 | 2,90 | 2,86 |
| Яңа Чишмә | 1,04 | 1,02 | 1,01 | 1,00 | 0,98 | 0,97 | 0,96 | 0,94 | 0,93 |
| Нурлат | 6,67 | 6,59 | 6,50 | 6,41 | 6,33 | 6,24 | 6,15 | 6,07 | 5,98 |
| Спас | 13,14 | 12,97 | 12,79 | 12,62 | 12,45 | 12,28 | 12,11 | 11,94 | 11,77 |
| Чирмешән | 1,06 | 1,05 | 1,03 | 1,02 | 1,01 | 0,99 | 0,98 | 0,96 | 0,95 |
| Чистай | 2,54 | 2,51 | 2,48 | 2,45 | 2,41 | 2,38 | 2,35 | 2,31 | 2,28 |
| Төньяк | 3,37 | 3,33 | 3,28 | 3,24 | 3,20 | 3,15 | 3,11 | 3,06 | 3,02 |
| Балтач | 3,10 | 3,06 | 3,02 | 2,98 | 2,94 | 2,90 | 2,86 | 2,82 | 2,78 |
| Кукмара | 2,68 | 2,64 | 2,61 | 2,57 | 2,54 | 2,50 | 2,47 | 2,43 | 2,4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мамадыш | 6,19 | 6,11 | 6,03 | 5,95 | 5,87 | 5,79 | 5,71 | 5,63 | 5,55 |
| Балык Бистәсе | 4,78 | 4,71 | 4,65 | 4,59 | 4,53 | 4,47 | 4,40 | 4,34 | 4,28 |
| Саба | 2,65 | 2,61 | 2,58 | 2,54 | 2,51 | 2,47 | 2,44 | 2,40 | 2,37 |
| Теләче | 3,42 | 3,37 | 3,33 | 3,28 | 3,24 | 3,19 | 3,15 | 3,10 | 3,06 |
| Көнбатыш | 16,57 | 16,36 | 16,14 | 15,93 | 15,71 | 15,50 | 15,28 | 15,07 | 14,85 |
| Апас | 3,45 | 3,40 | 3,36 | 3,31 | 3,27 | 3,22 | 3,18 | 3,13 | 3,09 |
| Буа | 29,58 | 29,19 | 28,81 | 28,42 | 28,04 | 27,65 | 27,27 | 26,88 | 26,5 |
| Чүпрәле | 3,55 | 3,50 | 3,46 | 3,41 | 3,36 | 3,32 | 3,27 | 3,23 | 3,18 |
| Кайбыч | 1,79 | 1,76 | 1,74 | 1,72 | 1,69 | 1,67 | 1,65 | 1,62 | 1,6 |
| Кама Тамагы | 2,99 | 2,95 | 2,91 | 2,87 | 2,84 | 2,80 | 2,76 | 2,72 | 2,68 |
| Тәтеш | 2,05 | 2,03 | 2,00 | 1,97 | 1,95 | 1,92 | 1,89 | 1,87 | 1,84»; |

7 нче таблицадан соң килә торган абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелә торган соңгы нәтиҗәләре, шулай ук Программа чараларын финанслау Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Моңа кадәр булган тәҗрибә икътисадый системада ТРПның үсешенә җитештерү һәм энергия ресурсларын куллану секторларында энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга һәм энергияне саклауга инвестицияләр кертү хисабына энергия кулланылышын сизелерлек дәрәҗәдә арттырмыйча ирешергә мөмкин булуын күрсәтә.

ТРПның энергия сыйдырышлылыгын Программа чараларын тормышка ашыру исәбеннән 26,1 процентка кадәр киметү өчен Программаның кирәкле финанслау күләме 33 531 718,5 мең сум тәшкил итәчәк.




15 нче рәсем. 2007 ел бәяләрендә ТРП динамикасы һәм үсеш фаразы (млрд.сум)




16 нчы рәсем. Беренчел энергия чыганакларын куллану динамикасы һәм фаразлары (ш.я.млн.т.)




17 нче рәсем. ТРПның энергия сыйдырышлылыгы динамикасы һәм фаразы (ш.я.т./млн. сум)

Программаны финанслауның гомуми күләме 33 531 718,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән 266 582,0 мең сумы – федераль бюджет акчасы исәбеннән, 2 423 321,1 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән, 30 841 815,4 мең сумы – бюджеттан тыш чыганаклардан.

Программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммалары чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.

Программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергия нәтиҗәлелеге һәм энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу

шартларында Россия Федерациясенең Энергетика министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән ел саен төзелә торган килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

Бюджеттан тыш акча исәбеннән энергияне саклау буенча гамәлдәге тармак программалары, республика предприятиеләренең һәм оешмаларының җитештерү (инвестиция) программалары кысаларында ягулык-энергетика комплексындагы, сәнәгатьтәге, төзелештәге, транспорттагы, торак-коммуналь комплекс объектларындагы һ.б.ш. төп чараларны финанслау гамәлгә ашырыла.

Чаралар һәм финанслау чыганаклары яктылыгында Программаның финанс ресурслары күләмнәре Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.»;

Программаның V бүлегендәге икенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаның нумерация башисемендә «2014 – 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин